КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 27 ноябрь г.Казань № 1062

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы халкын эш белән тәэмин итү өлкәсендә тармак инфраструктурасын оптимальләштерү турында» 2024 ел, 1 апрель, 208 нче карарына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы халкын эш белән тәэмин итү өлкәсендә тармак инфраструктурасын оптимальләштерү турында» 2024 ел, 1 апрель, 208 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 ел, 30 май, 378 нче, 2024 ел, 27 июнь, 474 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып), 2 пунктның дүртенче абзацында «760 берәмлек» сүзләрен «444 берәмлек» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

2. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына «Татарстан Республикасы халкын эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт казна учреждениесе хезмәткәрләренең штат санын киметү буенча законнарда каралган чаралар үткәрүне тәэмин итәргә.

3. Әлеге карар, карарның рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә торган 2 пунктыннан тыш, 2025 елның 1 февраленнән үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин